**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЛАШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ЛАШМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423110, Лашман авылы, Советлар урамы,55Айорт
Телефон (84396)2-92-35
Факс (84396) 2-92-35
Email: Lash.Cmn2@tatar.ru

423110. село Лашманка, ул.Советская д55А
Телефон (84396) 2-92-35
Факс (84396) 2-92-35
Email: Lash.Cmn2@tatar.ru


**30.09.2021** **№35**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Советының 2017 елның 8 августындагы 71 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бердәм башкарма орган буларак коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керүгә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы, «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Советының 2017 елның 8 августындагы 71 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бердәм башкарма орган буларак коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керүгә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 пункты «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Киләсе эчтәлектәге 2.1 пункты белән тулыландырырга: «2.1. Муниципаль хезмәткәрләрнең, түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуларын кабул итү:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференциядә) катнашу;

б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итү, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференциясендә) катнашу очракларыннан тыш) Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиле рөхсәте белән катнашу;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлек гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) булып торучы идарә органнарында һәм оешманың ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Лашман авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе: Р.Г.Фәттахов